| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан<br>Карашай-Сакловское<br>сельское поселение<br>Сармановского<br>муниципального района** | **Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Карашай-<br>Саклау<br>авыл җирлеге** |

| | |
|---|---|
| **КАРАР<br>22.11.2024 ел** | **КАРАР<br>№99/а** |

Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 12 ноябрендәге 15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, Сарман муниципаль районының «Карашай-Саклау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 12 ноябрендәге 15 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Салым ставкаларын күләмдә билгеләргә:

2.1. 0,1 процентка карата:

2.1.1. Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясындагы 2 пунктының 2 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән;

2.1.2. һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмалары;

2.2. 0,2 процентка карата:

2.2.1. фатирлар, фатир өлешләре;

2.2.2. бүлмә;

2.3. 0,3 процентка карата:

2.3.1. торак йорталар, торак йортларның өлешләре;

2.3.2. төзелеп бетмәгән объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;

2.3.3. составына бер генә булса да торак йорт кергән бердәм күчемсез комплекслар;

2.4. 2 процента карата:

2.4.1. Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

2.4.2. Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

2.4.3. һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектлары;

2.4.4. 2025-2027 еллар чорына 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга карата салым салу объектларына карата 2 процент, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган;

2.5. Башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлеге
Советы рәисе В.В.Хосниева